Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

08.06.2020 ел №16

Авыл җирлеге мөлкәте белән эш итү вәкаләтләрен муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Саба муниципаль районы Советы мөрәҗәгате һәм «sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өлеше" индикаторын үтәү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 21.01.2020 елдагы киңәшмәсе Беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итү турында:

- авыл җирлеге милке белән эш итү буенча;
- муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;
- әлеге карарны тормышка ашыру максатында, бюджет законнчалыкларына туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 2020 елга һәм 2021–2022 еллар план чорына бюджеты турында" 2019 елның 19 декабрендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" гы Карары проектын эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиахметов